РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ СТАРОКУРМАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423733, село Старое Курмашево,
ул. Центральная,дом 29,
Тел. 3-44-56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАС
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙО
ИСКЕ КОРМАШ АВЫЛ ЖИРЛЕ
СОВЕТЫ

423733, Иске Кормаш авылы
Үзәк ур., 29 нчы йорт. Тел.3-44-5

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«13» июль 2021 ел** **№ 13**

**Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Советының 07.09.2017 ел, № 22 «Иске Кормаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы норматив хокукый актларны Федераль законга туры китерү максатыннан, Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Советының 07.09.2017 ел №22 « Иске Кормаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 11.2. бүлеген түбәндәге эчтәлекле 13 пунктчасы белән тулыландырырга:

- «13) чит ил гражданлыгын алу вәкиленә, чит ил гражданлыгын алу яисә чит ил дәүләте территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алу турында, чит ил гражданлыгын алган көннән, биш эш көненнән дә соңга калмыйча, яисә чит ил дәүләте территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алу турында язма рәвештә хәбәр итәргә;»

1.2. 11.2 бүлегенең 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «9) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит дәүләт гражданлыгын туктату турында язма рәвештә хәбәр итәргә, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы, бу хакта муниципаль хезмәткә Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит дәүләт гражданлыгы туктатылганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә»;

1.3. 12 бүлекнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

-«6) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату;»

1.4. 28 бүлекнең 28.1 пунктының 2 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.5. 13.1 пунктының 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «7) чит ил гражданлыгы булу яисә, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;»

2. Әлеге карарны Иске Кормаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы
Иске Кормаш авыл җирлеге Советы рәисе И.Ә.Кашбразиев